*Мотыгуллина А. Р. (КФУ, Казань)*

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЕ КОММЕНТАРИИ – ОСНОВА ИЗУЧЕНИЯ ЛИТЕРАТУРНОГО ПРОИЗВЕДЕНИЯ

**Аннотация:** В статье раскрывается некоторые аспекты национально-культурологических комментариев на уроках татарской литературы. Культурологические комметарии в литературных произведениях непрерывно связаны с аксиологией, национальным колоритом, этнокультурными компонентами. Также обучение родной литературе основывается на духовно-личностные, нравственно-экологические проблемы.

**Ключевые слова:** национально-культурологический аспект, аксиология, искусство, этнокультура, эмпатическое общение, модель мира.

## National cultural kommentarii - the basis of the study of literary works

**Abstract:** The article deals with some aspects of the national kulturolovedcheskih comments on the lessons of the Tatar literature. Cultural Comment literary works continuously connected with axiology, national color, ethnic and cultural components. Also, training is based on the native literature of

spiritual and personal, moral and environmental problems.

**Keywords:** national-cultural aspect, axiology, arts, ethnic culture, empathic communication, model of the world.

Укучыларны мәдәни байлык белән таныштыруның төрле алымнары һәм чаралары яшәп килә. Әдәби әсәрләрне өйрәнгән вакытта мәдәни мәгълүматлар бирерлек урыннар күп очрый. Әдәбият дәресләрендә ул, күп очракта, тарихи-мәдәни мәгълүмат бирү буларак күзаллана. Мәдәни аңлатмалар бирү барышында аксиологик аспекттагы этномәдәният, әхлакый-экологик, рухи-шәхси, эмпатик (дини) сөйләшү, милли-мәдәни юнәлештәгеләренә киңрәк тукталу сорала [3, 75].

Әдәби әсәрне өйрәнгәндә этномәдәни юнәлештәге аңлатмалар бирерлек урыннар күп очрый. Алар, бер яктан, халыкның бай фольклор мирасы, мифологиясе белән бәйле темаларны үзләштерү барышында киң кулланылса, икенче яктан, матур әдәбият әсәрен үзләштерү барышында да аңлатма бирерлек урыннар шактый очрый. Мифологик мәгълүматларны хәзерге татар әдәбиятының күренекле вәкилләре А.Хәлим, Г.Гыйльманов, Н.Гыйматдинова, М.Кәбиров һ.б. әсәрләрен өйрәнү барышында бирерлек урыннар күп очрый. Алар, нигездә, сихер, магия белән бәйләнештә бирелә. Шуңа күрә күп очракта авторларның ирреальлек күренешенә мөрәҗәгать итүләре рәвешендә аңлатыла.

Мифик затлар һәм әкият геройлары белән дә очрашканда да шундый ук хәл күзәтелә. Мәсәлән, Шүрәле, йорт иясе кебек мифик образларны әдәби әсәрләрдә дә очратабыз. Мифик образ Шүрәлене мифологик хикәятләрдән алып язган Тукайга ияреп, сәнгатьтә (Бакый Урманче һ.б.) һәм әдәбиятта (Т.Миңнуллин "Шүрәле-җанкисәгем" һ.б.) күпсанлы сәнгать әсәрләре дөнья күрде. Йорт иясе образы М.Гыйләҗевның "Бичура"сында тудырыла. Шулай булгач, бу әсәрләрдәге аңлатмалар татар халык мифлары турындагы җыентыкларга мөрәҗәгать итүне сорый.

Милли-мәдәни аспектта аңлатма бирүнең тагын бер төре - әхлакый-экологик юнәлештә бара. Ул, бер яктан, табигать һәм кеше, табигать һәм җәмгыять мәсьәләләрен яктырта, икенче яктан, рухи экология рәвешендә дә гомумиләштерелә. Әдәбиятта табигать образларына мөрәҗәгать итү авторның натурфилософик карашларын ачу чарасы да булып

тора. Әдипләр табигатьне сакларга, кадерен белергә чакыралар, кеше һәм табигать мөнәсәбәтләрен шәхес һәм җәмгыять дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлыйлар. Бу үзенчәлек Г.Исхакыйның “Көз”, М.Әмирнең “Агыйдел”, Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек”, “Җидегән чишмә”, Н.Фәттахның “Итиль суы ака торур”, А.Гыйләҗевның “Әтәч менгән читәнгә”, Ә.Баянның “Тау ягы повесте”, Р.Мөхәммәдиевның “Ак кыялар турында хыял” әсәрләрендә аеруча ачык чагыла. Әдипләрнең табигатькә мөрәҗәгать итүенең төп сәбәбе матурлык тудыру сәләте белән бәйләнгән. Бу нисбәттән Ә.Еники аерым игътибарга лаек. Әдип иҗатында табигать күренешләрен кешенең күңел дөньясын, эчке халәтен ачуга йөз тотып, “Саз чәчәгендәге” чәчәкләр, “Рәшә”дәге дала, “Тауларга карап”тагы биек таулар, “Туган туфрак”тагы Питрәчнең көлсу туфрагы, “Төнге тамчылар”, “Бер сүз”дәге язгы табигать, “Тынычлану”дагы җәйге эсселек рәвешендә сурәтләү, аның табигать тасвирларына олы идея-эстетик бурычлар йөкләвен күрсәтә. Шул рәвешле, Ә.Еники иҗатында кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәтләрнең тирән, эчке бәйләнештә бирелүе, бер яктан, пейзаж тасвирын бирү, икенче яктан, типик халәтне сурәтләү кеше характерын ачуда кулланылган ике параллель алым гына түгел, ә бәлки бер алымның, синтезлашкан бербөтеннең ике ягы, ике юнәлеше булып тора. Нәкъ шушы аспект Ә.Еники әсәрләренә салынган мәгънәне аңлатканда үзәккә алынырга тиеш.

Мәдәни аңлатмалар бирү барышында этик тәрбия бирүне алгы планга куйган рухи-шәхси юнәлешне дә игътибардан читтә калдырып булмый. Рухи байлыклар турында сөйләү нәтиҗәсендә тормыш һәм яшәештәге кыйммәтләргә дә тукталып барабыз. Шуңа күрә әхлакый табышларыбызны дәрестән дәрескә үстереп, киңәйтеп, милли үзенчәлекләрне ачу дәрәҗәсендә нәтиҗә ясыйбыз.

Татар әдәбияты дәресләрендә милли-мәдәни сөйләшүгә (диалог) корылган аңлатмалар да бирелеп барыла. Халык тормышындагы әхлакый һәм рухи кыйммәтләрне барлау, бәяләү аерым урын алып тора. Ул урта сыйныфларда эмпатик (дини) диалогка корылса, югары сыйныфларда дөньяны кабул итүдә илдәге һәм дөньядагы бөек казанышларны бәяләү ягында барырга мөмкин. 1990 нчы еллардагы үзгәрешләрдән соң эмпатик әңгәмәгә корылган әсәрләргә аерым игъ-

тибар юнәлтелә башлады. Г.Исхакый “Кәҗүл читек” хикәясендә, “Зөләйха” драмасында, “Көз” повестенда, Ф.Әмирханның “Гарәфә кич төшемдә”, “Хәят” әсәрләрендә ислам дине тәгълиматларын, дин бәйрәмнәре, йолалары турында мәгълүмат бирелү шул юнәлешне күздә тота.

Әдәби әсәрләрне мәдәни аспектта өйрәнүне өч ракурста (юнәлештә) оештырырга мөмкин: гомумиләштерелгән дөнья моделен кору, милли-мәдәни галәм, автор тудырган дөнья сурәте һәм кеше. Аларда әдипнең фәлсәфи, дини, әхлакый, эстетик карашлары аша, яки архетиплар (әби), мотив, миф, символлар аша тәкъдим ителә. Бу әсәрләрдәге ачыш-табышлар гомумкешелек һәм милли якны ачу чарасына әверелә. Мәдәният һәрвакытта халыкның индивидуаль ягын чагылдыра, кешелек җәмгыятеннән аерылгысыз була. Мәдәни анализ ясау әсәрнең моңа кадәр игътибардан читтә калган якларын ачарга ярдәм итә.

Әдәби әсәргә мәдәни якын килүнең асылы шуннан гыйбарәт: анда мәдәни тормышны дәлилләүче күренешләр генә сурәтләнми, ә культурологик мәгълүматлар әдәби әсәрнең образлар системасы аша, аның кысасындагы вакыйгалар яктыртылуга йөз тотыла. Әйтик Г.Исхакыйның “Җан Баевич” комедиясендә татар халкының мәдәни яктан артталыгын, элекке традицияләрнең искерүен, ләкин яңалары белән алмашына алмавы тәнкыйтьләнә.

Г.Исхакый Җан Баевичның культуралы булырга омтылышын берничә юнәлештә ача: беренчедән, ул яшәгән йортның интерьерын бирә (“Зур бер зал. Бер почмагында зәңгәр вә яшел төсле урындыклар. Бер почмагында ак буяулы хатын-кыз шкафы. Бер почмагында озын рояль. Аның өстенә әллә никадәр кылычлар, мылтыклар асылынган, көзгенең башларына кош гәүдәләре эленгән. Урта бер җирендә ябыла торган биек язу өстәле. Диварда алтын рамда Шакирҗанның зур иттереп эшләнгән үз рәсеме, аның бер ягында солтан рәсеме, бер ягында бер урядник рәсеме. Диварларда әллә ничә төрле сәгатьләр, кайсыберсе уйный торган, кайсыберсе уята торган.“, икенчедән, Шакирҗанның киенү рәвешен тасвирлый (“Аның өстендә фрак, муен бавы ачык кызылдан, жилеты яшел төстә. Аягына ак туфли берлә сары гетр кигән.”), өченчедән, сөйләме һәм теләк-омтылышлары белән (мине һәрвакыт “господин Җан Баевич” дип дәшәргә). Бу нинди тәрәккый пәрвәр түгеллек. Необразованный безнең татар халкы. Әйе, фрүләен Халидәне

бирегә тәшриф җәнаб иттер. Мин сезнең кебек камыр басу, самовар куюларны гына уйламыйм. Дөньяның йөреше, дөньяны образованныйлаштыру хакында төшенәм. Без хәзер андый вак татар эшләреннән, татарның необразованный гадәтләреннән үскән. Мин хәзер собственный дом Горчичный улица имею, мин хәзер Җан Баевич, обазованныйлыкка сезне өйрәтәм. Бу – господин Җан Баевичның уйлау вакыты үтте. Ул – үзенең тирән, зур, олуг-бөек уйларыны үзенең зур башында уйлап бетерде дигән сүз. Менә бу көн син, затсыз, комачауладың, господин Җан Баевич бу дөньяның хәле хакында рәтләп уйлый алмады. Ни булыр бу дөньяга? Кызганыч бу дөньяның зәгыйфь адәм балалары!.. Шул шайтанга алданып никадәр дәүләт бетердем, никадәр дәүләт!.. Мин бит тәрәккый пәрвәр булдым дип белдем!.. Мин бит тарихка керәм дип белдем!, - дип башкалардан аерылып торырга тырыша. [1: 22-28]

Татар әдәбияты дәресләрендә кеше һәм табигать, җир шары арасындагы мөнәсәбәтләрне өйрәнүгә аерым игътибар итәбез. Ул гуманистик күзаллау, милли үзаң, экологик мәдәният булдыруда үзәк булып тора. Башлангыч һәм урта сыйныфларда ул кеше һәм җанлы табигать арасындагы мөнәсәбәтләрнең әхлак проблемасы яктылыгында чишелешенә игътибар итсәк, югары сыйныфларда яшәешнең глобальрәк проблемаларына (кеше һәм эволюцион үсеш, кеше һәм ноосфера) тукталына. Мисал итеп Г.Кутуйның “Сагыну” нәсерендә табигать сурәтләнешенә игътибар итсәк, анда туган җир, су, тау, әрем символик образлары билгеле бер төбәктә яшәгән халыкның милли хәзинәсе дәрәҗәсендә тасвирлана. Шул рәвешле, әсәрдәге табигать мотивлары гомуммилли топос дәрәҗәсенә күтәрелә.

Әдәби әсәрләрне мәдәни аспектта өйрәнүнең бер тармагы гомумиләштерелгән дөнья моделен коруга бәйле. Ул һәр әдипнең шәхси күзаллавына, дөньяга карашын ачыклауга барып тоташа. Шундый эпик киңлекне Айдар Хәлимнең “Кыйбла” хикәясендә очратабыз. Аны хәтта Ә.Дусайлы дастанга тартым әсәр дип атый. Кыйбла әсәрдә берничә мәгънәдә ачыла: беренчедән, мөселманнар карап дога кыла торган көньяк, икенчедән, җылылык, яктылык юнәлеше. Ә әсәр геройлары исә үзләре өчен кыйбла эзлиләр. Авылдан куылып чыгып киткәндә кыйбла – юнәлеш, икенчедән, намуслы гаиләнең йөз аклыгы, гаиләдәге тугрылык, сабые үлгән хатын өчен җир куенында гына булса да баласына

уңайлы урын эзләү.

Бер гаилә моделе мисалында автор кыйбланы табуга ирешә: ир белән хатын бер фикердә (ул азсүзлелек аша ачыла), икесе дә ил тарихының сынауларын узганнар. Аеруча Гарифулла белән бәйле булган аерым аңлатмалар бирүне сорый. Ул Октябрь түнтәрелеше елларында дөньяга килеп, гарәп имлясыннан латинга күчкәндә аңа ундүрт яшь була. 1934 нче елда әтисе ярлы крәстиян дип язып биргәнлектән Бәләбәй укытучылар техникумына укырга керә. Колхозга көчләп кертү, салым түләтү мәзин Садретдин гаиләсен читләтеп үтми. Алар бер төн эчендә барлык гаиләләре белән җыелып, иң кирәкле әйберләрне генә алып, авылдан чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Калган малмөлкәткә мөнәсәбәт мәзин Садретдин авызыннан әйтелә: “Качып китсәң дә, чәчеп кит, дигән борынгылар!...” [2, 12]

Гарифулла гомере буе ил өстенә килгән афәтне кичереп, фашист концлагерьларын үтеп, үз илендә аңлау тапмыйча яши. Хатыны Өммегөлсем исә тагын да авыррак язмышка дучар була. Беренчедән, татар-үзбәк арасындагы мөнәсәбәтләрне корбаны була, икенчедән, татарлар арасында үзара аңлашу булмауны күреп борчыла. Татар кешесе булуга да карамастан, русларның аның халәтен тизрәк аңлауларына аптырый. Гомумән, әсәр дәвамында укучыларга СССР таркалуның сәбәпләрен аңлату, төрле милләт вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең төрле шартларда яшәешен, көнкүрешен ачыкларга тиеш булабыз.

Укучыларга мәдәни аңлатмалар бирү әдәби әсәргә салынган вакыйгалар һәм автор позициясе белән бәйле. Татар әдәбияты тарихында мәдәни аңлатмалар бирү күбрәк мәдәни-тарихи (тарихи әсәрләр: М.Хәбибуллинның “Кубрат хан”), мәдәни-фәлсәфи (З.Хөсниярның “Терсәк сугышы” “Эттән туган” дилогиясендә Ницше фәлсәфәсе), хәтта саф мәдәни (Ф.Хөснинең “Рубенс” хикәясе) аңлатмалар рәвешендә күзаллана. Мәдәни аңлатмалар бирү әдәби әсәрнең язылу ысулына бәйле рәвештә дә үзгәрә. Мәсәлән, драма әсәрләрен өйрәнү барышында лирик башлангычның көчле булуы андагы җыр текстлары белән бәйле. М.Фәйзинең “Галиябану”, К.Тинчуринның “Зәңгәр шәл”, Т.Миңнуллинның “Әлдермештән Әлмәндәр” һ.б. әсәрләрдә персонажларның рухи халәтен ачу өчен җырларга салынган мәгънәне ачарга тиеш булабыз.

Гомумән алганда, әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында мәдәни аңлатмалар бирү

өчен мөмкинлекләр киңкырлы икән. Алар әдипләрнең чор картинасын тудыру осталына, әдәби образларны сурәтләү сәләтенә һәм идея-эстетик карашларына бәйле рәвештә үзгәреп тору сәбәпле, бер калыпка гына сыеп та бетми.

Файдаланылган әдәбият исемлеге:

1. Исхакый Г. Зиндан /Г.Исхакый// Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

2. Хәлим Айдар. Татар моңы / Айдар Хәлим// хикәяләр, повесть, роман – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 383 б.

3. Черкезова М.В. Проблемы преподавания русской литературы в инокультурной среде / М.В Черкезова // методическое пособие - М.: Дрофа, 2007. – 318 с.